СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ГОРОД ИННОПОЛИС»
ул. Спортивная, д.114, г.Иннополис,
Верхнеуслонский район, Республика
Татарстан, 420500

МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕНЕҢ
«ИННОПОЛИС ШӘҺӘРЕ»
СОВЕТЫ
Спортивная ур., 114-нче йорт, Иннополис
шәһәре, Югары Ослан районы, Татарстан
Республикасы, 420500

тел. (843) 212-27-24, e-mail: city@innopolis.ru, www.verhniy-uslon.tatarstan.ru/rus/innopolis.htm

РЕШЕНИЕ КАРАР

29.04.2022 8-52
№

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәт белән идарә итү һәм эш итү тәртибе турында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге гражданнарының 2017 елның 13 ноябрендәге 2 нче номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күчемсез милекне дәүләт теркәвенә алу турында» 2015 елның 13 июлендәге 218-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Икътисадый үсеш Министрлыгының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль милек реестрларын алып бару тәртибен раслау турында» 2011 елның 30 августындагы 424 номерлы боерыгы нигезендә,

«Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге Советы

Карар итте:

1. Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендәге мөлкәт белән идарә итү һәм аның белән эш итү тәртибе турында Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге гражданнарының егерме өченче җыенының 2017 елның 13 ноябрендәге 2 номерлы карары белән расланган Нигезләмәгә (алга таба – нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 2.6 пунктының өченче абзацында түбәндәге эчтәлекле сүзләрне төшереп калдырырга: «шул исәптән аны хосусыйлаштыру турында».;

1.2. Нигезләмәнең 3.4 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «3) аренда хокуклары – арендаторлар; ышанычлы идарә итү-ышанычлы идарәчеләр»;

1.3. Нигезләмәнең 4.1. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. РФ Икътисадый үсеш Министрлыгының «Җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль милек реестрларын алып бару тәртибен раслау турында» 2011 елның 30 августындагы 424 номерлы боерыгы нигезендә, Иннополис шәһәренең муниципаль милке Реестрында мәҗбүри исәпкә алынырга тиеш:

- муниципаль милектәге күчемсез милек (бина, төзелмә, корылма яки төзелеп бетмәгән төзелеш объекты, җир участогы, торак, торак булмаган бина яки җир белән нык бәйләнгән бүтән объект, аның билгеләнешенә зыян китермичә күчүе мөмкин булмаган, яки закон белән күчемсез милеккә караган башка мөлкәт);

- муниципаль милектәге күчемсез милек, хуҗалык җәмгыятенең яки ширкәтнең устав (склад) капиталында өлешләре (кертемнәре) яисә бәясе Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге вәкиллекле органы карары белән билгеләнгән күләмнән артып киткән күчемсез милек, шулай ук аеруча кыйммәтле күчемсез милек, автоном һәм бюджет учреждениеләренә беркетелгән һәм «Автоном учреждениеләр турында» 2006 елның 3 ноябрендәге 174-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коммерцияле булмаган оешмалар турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 7-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә билгеләнгән күчемсез милек;

- Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге карамагындагы муниципаль унитар предприятиеләр, муниципаль учреждениеләр, хуҗалык җәмгыятьләре, ширкәтләр, акцияләр (кертемнәр), аларны гамәлгә куючы (катнашучысы) муниципаль берәмлек булган башка юридик затлар»;

1.4. Нигезләмәнең 4.4. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендә булган муниципаль милекне исәпкә алу максатыннан Иннополис шәһәренең муниципаль милке Реестрында Иннополис шәһәре Башкарма комитеты тиешле карар кабул итә.»;

1.5. Нигезләмәнең 4.5. пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының «Иннополис шәһәре» муниципаль берәмлеге милкендә булган муниципаль милек белән идарә итү реестрга кертелгәнче рөхсәт ителми.»;

1.6. Нигезләмәнең 9.2. пунктының абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Муниципаль милек, сәүдә үткәрмичә генә, Иннополис шәһәре Башкарма комитеты карары буенча, федераль законнарда билгеләнгән очракларда, түләүсез файдалануга бирелергә мөмкин.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы Муниципаль

берәмлекләре порталы составында Интернет челтәрендә Югары Ослан муниципаль районының мәгълүмат сайтында (http://verhniy-uslon.tatarstan.ru), шулай ук Иннополис шәһәре мэриясе бинасында урнашкан махсус мәгълүмат стендында урнаштырырга.

Совет рәисе,
Иннополис шәһәре Мэры Р.Р. Шагалеев